

Жир йозендә һәр кешенен vз юлы, vз сукмагы бар. Шуна кvрә тормыш бизәкләре кешеләргә торле урында һәм торле вакытта шатлык китерсә, киртә булырга теләгән таулары да зур сынау булып, торле кешегә торле вакытта очрый. Кемнәрдер, чынлап та, алга барудан туктап кала һәм әйләнгеч, жинелрәк сукмакларны эзли башлый. Ә кемнәрдер, каршылыкларны жинә-жинә, алга баруын дәвам итә. Гадәттә андый кешеләр тыйнак та, горур да, дәрәжәле дә, шул ук вакытта гади дә булалар.Үз-vзенә һәм башкаларга таләпчәнлек, хезмәт соючәнлек, тырышлык һәм эшне ахырына кадәр житкерә белv, туры сvзле булу - андыйларнын асыл сыйфатлары. Халык арасында зур хормәт казанган кешеләр белән башкалар санлаша, алардан vрнәк алалар, кинәш сорыйлар. Ә ин моһиме – мондый кешеләрнен, гадәттә, балалары да тәртипле була. Торбеево районы Татар Юнәсе авылында туып-vскән Раис Равил улы Салихметовка шундый сvзләр туры килә. Ата-балаларыбыз гомер-гомергә, буыннан-буынга эшләп, һәрвакыт зур унышларга, авыл хужалыгы продукциясенә омет баглап яшәде. Бvген дә шулай һәм Раис Равил улы гомере буе туган туфрагында хезмәт итә. Зур эш тәжрибәсе, белемлелеге, эшне, халыкны яратуы житәкче буларак унышларга ирешергә ярдәм итеп килә; алдынгылар рәтенә чыгара. Мордовия авыл хужалыгы олкәсендә Атказанган хезмәткәр (Заслуженный работник сельского хазяйства РМ), торле грамоталары һәм димломнары, бvләкләре бу турыда сойли.

- Раис Равил улы Салихметов - булдыклы, vз эшенен остасы, талантлы, олысы-кечесе белән уртак тел таба ала. Яналыкка омтылудагы кыюлыгы белән ул безне һәрвакыт сокландыра һәм vзенә карата зур хормәт уята. Хезмәтенә ботен кvнелен биреп башкаручы  житәкче эшен һәрвакыт уйлап, ахырына кадәр житкерә белә. Зур ышандыру коченә ия булган якташым vз фикерен беркайчан да кочләп такмый, кешеләрнен хәтерен калдырмыйча, әдәпле итеп сойләшә. Мәктәбебезгә, кирәк чакта, спонсорлык ярдәмен дә кvрсәтә. Юнки халкы анардан кинәш сорыйлар, vрнәк алалар, хормәт итәләр, - диде анын турында зур стажлы мәктәп директоры Тәнзилә Әхмәт кызы Агишева.

Язма героебыз турында берничә сvз. Раис Равил улы Салихметов 1948 елнын 7 январендә Торбеево районы Татар Юнәсе авылында доньяга килә. Тырыш, хезмәт соючән гаиләдә vсә, тәрбия ала ул. Әтисе - Равил Хәсән улы, Боек Ватан сугышы ветераны, гомере буе колхоз тракторлары бригадасы бригадиры буларак авыл халкынын

хормәтен яулаган кеше. Әнисе - Шәфика Хәмзә кызы, тормыш иптәше белән бергә шулай ук тракторлар бригадасында эшли, әмма учетчица булып. Алар биш бала - дvрт малай һәм бер кызга тормыш бирәләр. Оч баласы вузда белем ала: Зәкияләре - физика һәм математика белгечлеге ала, Раис белән Хәйдәрләре - агроном профессиясен vзләштерәләр. Раис Равил улы, Юнәдә жиде еллык мәктәп булганга, урта белем алу теләге белән, алты километр ераклыкта урнашкан Митрялыда (1961-65 елларда) унбер класс тәмамлый. Алты-жиде яшьтәш бергә кышларын – лыжаларда, язларын – велосипедларда ике авыл арасында йореп белем алганнар. Барлык предметлар белән берлектә, татар теле һәм әдәбиятын vзләштергәннәр; шуна Раис Равил улы белән иркен татар телендә аралаштык.
Мәктәпне унышлы тәмамлап, агроном профессиясен vзләштереп, 1970 елда туган авылындагы «Нариман» колхозында агроном буларак хезмәт биографиясен башлап жибәрә Раис Равилевич. Шулай ике ел агроном булып эшли, аннары - бер ел Совет Армиясе сафында хезмәт итә. 1974 елда туган авылына кайтып агрономлык эшен дәвам итә. Ил хастәрен чын иргә йоклиләр: 1975 елнын мартында Юнә халкы авыллары колхозы председателе буларак сайлыйлар Раис Равил улы Салихметовны. Шуннан 11 ел дәвамында колхоз председателе булып хезмәт итә. Биредә ул чын тормыш мәктәбен vтә. Колхозлар таралгач, тик торырга яратмаган житәкче, ООО «Юнки» сельхозкооперативын булдыра. Бvген анын ике менгә якын гектар жирендә уртача гектарыннан 23,5 центнер ( 2006-08 елларда – 30-35 центнер) алып ашлык vстерә, 103 баш савым сыерыннан елына бер сыердан 3800 килограмм сот житештерә һәм 50ләп бозау асрый. Анын хужалыгында 15 кеше эшли, ә уныш жыйганда эшләvчеләрнен саны утызга житә.
- Туган жирдә хезмәт итv бигрәк кvнелле, шуна да vземне бик бәхетле хис итәм. Билгеле, югары унышларга ирешv очен жин сызганып эшләргә кирәк. Кvп вакыт, барлыкка килгән авырлык-лардан чыгу юлын эзли-эзли, хезмәт итәргә туры килә. Кайберләрен чишеп тә булмый кала. Ин моһиме – эшне урынына житкереп, яратып башкарырга кирәк. Без vз эшчәнлегебез белән дәvләт программаларын vтибез, - ди житәкче Салихметов.
Эшендә дә, оендә дә тәртип анын. Тормыш иптә-ше Нәфисә Абдрахман кызы белән бер-берсен кырык елдан артык анлашып, дус һәм бәхетле тормыш итәләр. «Яраткан эшем, янәшәмдә мине ярты сvздән анлаучы, дәрт-дәрман остәп торучы хатыным булу да зур бәхет бит ул», - болар Раис  Равил улынын  йорәк тvреннән чыккан сvзләре. Нәфисә Абдрахман кызы Татар  Юнәсе мәктәбендә озак еллар тырышып татар теле һәм әдәбиятын укытты; андыйлар турында чын укытучы, диләр. Бvген лаеклы ялда, әмма тавык - казларын vрчетә, бакчасында яшелчәләрен vстерә. Хоббисы анын – матур әдәбият әсәрләре уку һәм чәчәкләр vстерv; ое голгә кvмелгән. Раис Равил улы белән Нәфисә Абдрахман кызы ике кыз бала - Венера белән Фаиләне тәрбияләп vстергәннәр; берничәшәр югары белем алган профессионаллар бvген алар. Фаилә Раис кызы Мәскәvдә юрист буларак милек (недвижимость) конторасында унышлы хезмәт итә. Венералары да Мәскәvдә яши. Ул башлангыч сыйныф укытучысы да, директор урынбасары да буларак хормәтле кеше. 7 сыйныфта укучы Крестина кызлары да, әти-әнисе тосле, гел бишле билгеләренә генә укый. Каникулларында, татар авылынын татар мохитенә чумып, Юнә әби-бабасында ял итә.
Раис Равил улы Салихметовка 7 январьдә 70 яшь тула. Безнен юбиляр кешелекле, кочле рухлы, булдыклы,  ярдәмчел кеше һәм ышанычны һәрвакыт аклый. Ул тормышта vз юлын,

vз сукмагын булдырган. Киләчәктә исәнлек-саулык, бәхетле тормыш, халыкны һәм туган туфрагын яратучы житәкчегә тагы да зур уньшларга ирешергә насыйп итсен. Ана шулай ук оптимист, тирә-яктагыларга жирдә яхшы кешеләр булуына ышаныч бирә торган кеше булып калуын телисе килә.

**Наилә Насырова**